ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.06.2016 Балык Бистәсе штп. № 151пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны банк белән озата баруны гамәлгә ашыру очракларын билгеләү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрактларны банк белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру турында» 2014елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны банк белән тәэмин итү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары белән расланган контрактларны банк ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыру кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

1.1)банкның тәэмин итүче яисә заказчы тарафыннан җәлеп ителгән контрактны уздыруда төзелә торган контрактын банк озата баруга карата контракт үтәлеше кысаларында исәп-хисаплар мониторингы, әгәр контрактның башлангыч (максималь) бәясе, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе кимендә 200 млн. сум тәшкил итсә.

1.2)бергә бара торган контрактны үтәү кысаларында башкарыла торган исәп-хисаплар мониторингын үткәрүгә өстәмә буларак контрактны банк озата баруга карата, банк тарафыннан кабул ителә торган товарларның, эшләрнең (аларның нәтиҗәләренең), контракт шартларына (киңәйтелгән банк озатылуы) туры килүен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган башка хезмәтләр күрсәтүгә (контрактның башлангыч (максималь) бәясе, контрактның бердәнбер тәэмин

итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе кимендә 5 млрд. сум тәшкил итсә.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Муниципаль заказ хезмәте» муниципаль казна учреждениесенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин